**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Елаур
авылы

КАРАР

«30» октябрь 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Елаур авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Елаур авылы, Центральная урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авылының Үзәк урам буенча 1-85нче, Яшьләр урамы буенча 3-25нче, Пионер урамы буенча 2-5нче, Комсомол урамы буенча 5-23нче, Чапаев урамы буенча 1-22 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 12 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Елаур авылы, Центральная урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авылының Ленин урамы буенча 1-69нчы, Калинин урамы буенча 1-68нче, Елга арьягы урамы буенча 4-14нче, Җиңүнең 40 еллыгы урамы буенча 2-10 нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Елаур авылында яшәүчеләр җыенын уздыру өчен исемлекне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Елаур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.
2) Урамнарны яктырту (ремонт, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы В.В.Охототникова